СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**
**16.08.2016**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 115**

2016 елның беренче яртыеллыгында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту турында

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының финанс – бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе О. П. Дёгтеваның 2016 елның беренче яртыеллыгында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту турында мәгълүматын тыңлаганнан соң һәм фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясына, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә таянып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. 2016 елның беренче яртыеллыгында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту турында мәгълүматны игътибарга алырга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**

Зеленодольск муниципаль район Советының 2016 елның 16 августындагы 115 номерлы карарына кушымта

*2016 елның 1 июленә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту турында мәгълүмат*

| *№ п/п* | *Түләүне билгеләү* | *Сумма (сум)* |
|---|---|---|
| 1 | Янгыннан зыян күрүчеләргә матди ярдәм күрсәтү | 93 060,00 |
| 2 | Дәвалану өчен матди ярдәм күрсәтү | 50 000,00 |
| 3 | Башка төр матди ярдәм күрсәтү | 80 000,00 |
| 4 | «Сабантуй-2016» татар милли бәйрәмен уздыру | 1 176 180,22 |
| 5 | Крещение бәйрәме көннәрендә юлларны җыештыру, шул исәптән: «Раифа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге - 43 200 (кырык өч мең ике йөз), «Әйшә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге – 39 999 (утыз тугыз мең тугыз йөз туксан тугыз ) сум 99 тиен. | 83 199,99 |
| 6 | Административ комиссия эшчәнлеге белән бәйле почта чыгымнарын түләү өчен | 50 000,00 |
| 7 | Зеленодольск шәһәре, Сәйдәшев ур., 15 йорт адресы буенча урнашкан фасадны ремонтлау-торгызу эшләренә һәм фасадны тышкы бизәкләү эшләренә түләү өчен | 583 783,67 |
| 8 | Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 71 еллыгына багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру өчен «Гари поселогы» территориаль иҗтимагый үзидарәсенә матди ярдәм күрсәтү (Җиңү скверын төзү һәм җиһазлау эшен тәмамлау) | 100 000,00 |
| 9 | «Буран» СП режимын өлешчә кертү сәбәпле, Зеленодольск шәһәренең урам-юл челтәрен кардан чистарту өчен (билгеләнгән урыннарда карны чыгару һәм ташлауны да кертеп), "Коммуналь хуҗалык" МУП чыгымнарын компенсацияләү өчен | 999 657,86 |
| 10 | Мактаулы гражданнарның вафатына бәйле рәвештә матди ярдәм күрсәтү | 25 000,00 |
| *БАРЛЫГЫ* | | *3 240 881,74* |